КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1275

2019 – 2020 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 ел, 21 декабрь, ФЗ-178 нче һәм «Акционерлар җәмгыятьләре турында» 1995 ел, 26 декабрь, ФЗ-208 нче федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләргә Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләргә:

махсус хокуктан («алтын акция»дән) файдалану турында карар кабул ителгән акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына бу карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә;

махсус хокуктан («алтын акция»дән) файдалану турында карар кабул ителгән акционерлар җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә.

акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган «Югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» Технополис» инновацион индустриаль паркы – технопаркы» ачык акционерлар җәмгыятенең директорлар советына бу карарга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә;

акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган «Югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» Технополис» инновацион индустриаль паркы – технопаркы» ачык акционерлар җәмгыятенең ревизия комиссиясенә бу карарга теркәлгән 4 нче кушымта нигезендә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советына тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеген;

акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеген;

акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советына Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан тәкъдим итү һәм билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеген.

3. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турындагы хәбәрнамәләрне бу карарга теркәлгән кушымталарда һәм бу карар белән расланган исемлекләрдә күрсәтелгән акционерлар җәмгыятьләренә «Акционерлар җәмгыятьләре турында» 1995 ел, 26 декабрь, ФЗ-208 нче Федераль закон белән билгеләнгән вакытларда җибәрергә.

4. 2019 елда бу карар белән расланган исемлекләрдә һәм аңа теркәлгән кушымталарда күрсәтелгән акционерлар җәмгыятьләрендә акционерларның еллык гомуми җыелышларын үткәргәннән соң һәм идарә һәм тикшерү органнарының яңа составын формалаштырганнан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«2018 – 2019 елларга Татарстан Республи-касы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында» 2017 ел, 22 декабрь,1023 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2019 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1023 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 ел, 9 март, 140 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2019 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советла-рына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1023 нче карары белән расланган Акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советына Татарстан Республика-сының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан тәкъдим итү һәм билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 5 сентябрь, 753 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 – 2019 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында» 2017 ел, 22 декабрь, 1023 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 27 ноябрь, 1063 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин